КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 август г.Казань № 679

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт органнарын һәм башка органнарны хезмәттәге ведомство аерымлык билгеләре Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә исәпкә алына торган органнар исемлегенә кертү тәртибе һәм шартлары турында» 2012 ел, 13 март, 210 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт органнарын һәм башка органнарны хезмәттәге ведомство аерымлык билгеләре Татарстан Республикасында «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә исәпкә алына торган органнар исемлегенә кертү тәртибе һәм шартлары турында» 2012 ел, 13 март, 210 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 19 сентябрь, 655 нче; 2017 ел, 26 июнь, 438 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигезләмә һәм исемлек 2016 елның 30 июненә кадәр хезмәттә ведомство аерымлык билгесе белән бүләкләнгән гражданнарга карата кулланыла;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эшчәнлекләре белән идарә итүне Россия Федерациясе Хөкүмәте гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимият органнарының, бүтән федераль дәүләт органнарының, дәүләт корпорацияләренең бүләкләү 2016 елның 1 июленнән соң, алар «Хезмәт ветераны» исемен бирү хокукын билгеләүче ведомство аерма билгеләрен гамәлгә куя торган тиешле норматив хокукый акт

кабул иткәнгә кадәр гамәлгә ашырылган ведомство аерма билгеләре «Хезмәт ветераны» исемен биргәндә исәпкә алына.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин